# ГОСУДАРСТВЕННЫЙ ФОЛЬКЛОРНЫЙ АНСАМБЛЬ КРЯШЕН БЕРМЯНЧЕК

ГОСУДАРСТВЕННЫЙ ФОЛЬКЛОРНЫЙ АНСАМБЛЬ КРЯШЕН БЕРМЯНЧЕК



КАЗАНЬ 2018

МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

# БӘРМӘНЧЕК КЕРӘШЕННӘРНЕҢ ДӘҮЛӘТ ФОЛЬКЛОР АНСАМБЛЕ

БӘРМӘНЧЕК КЕРӘШЕННӘРНЕҢ ДӘҮЛӘТ ФОЛЬКЛОР АНСАМБЛЕ



Бермянчек

## Бәрмәнчек

Керәшеннәр саклап калган
Олы бәйрәм – бәрмәнчек!
Аны бүген дә сагына
Бөек Болгар, Кирмәнчек...

Төркиләрдән бүгенгәчә
Тарихны бизәп килә.
Аны ханнар, президентлар,
Зур милли бәйрәм, дия!..

"Бәрмәнчек" дип исем бирдек
Өр-яңа ансамбльгә.
Җыр-биюне сагынсагыз,
Килегез, дуслар безгә,
Килегез "Бәрмәнчек"кә!..

Григорий Родионов,
Татарстанның халык язучысы

“Бәрмәнчек, һәрчак балкы, соклансын дөнья халкы!”

Бермянчек – в переводе означает верба. Это древний символ, одно из воплощений Древа Жизни. Верба олицетворяет плодородие, здоровье, радость и считается символом непрерывности и постоянства жизни. Верба первая извещает о приходе весны. Пробудившееся первым после долгой зимы, это деревце наделяется в народе огромной силой. В христианской традиции верба является атрибутом одного из главных православных праздников – Вербного воскресения.



# ИСТОРИЯ АНСАМБЛЯ

Ансамбль «Бермянчек» был создан в феврале 2008 года по инициативе Общественной организации кряшен Республики Татарстан, при поддержке Президента Татарстана Минтимера Шаймиева, Правительства и Министерства культуры республики. Однако истоки ансамбля берут начало в 2002 году, когда на базе Казанского государственного университета культуры и искусств был создан молодежный фольклорный ансамбль кряшен «Бермянчек». Первыми участниками ансамбля стали студенты факультета национального искусства университета культуры Оксана Дмитриева, Сергей Гладков, Снежана Абрамова, Алексей Савельев, Римма Никитина, Лиана Миронова, а также студентки Казанской государственной консерватории имени Нажиба Жиганова Вера Васильева и Светлана Матвеева. Художественным руководителем ансамбля стал известный фольклорист, этномузыколог, кандидат искусствоведения Геннадий Макаров.

Спустя шесть лет руководство республики Постановлением Кабинета Министров Татарстана № 73 от 11 февраля 2008 года объявило о создании государственного бюджетного учреждения культуры Республики Татарстан «Государственный ансамбль кряшен «Бермянчек». Директором ансамбля был назначен заслуженный работник культуры Геннадий Григорьевич Максимов.

К этому времени Геннадием Макаровым уже был подготовлен основной состав ансамбля. Также в новообразованный ансамбль были приглашены опытные артисты из других коллективов республики. Можно сказать, что Геннадий Михайлович не просто стоял у истоков создания ансамбля, но и на протяжении всего времени его существования является точкой опоры для каждого члена коллектива. Благодаря его богатому опыту и профессиональному чутью «Бермянчек» в короткие сроки снискал славу не только в Татарстане, но и по всей России.

Сегодняшний репертуар ансамбля «Бермянчек» – это результат многолетних этнографических экспедиций Геннадия Макарова, в которых он собрал уникальные и разноплановые образцы различных территориальных групп кряшен. Радует, что и сегодня эта работа продолжается Геннадием Михайловичем и его студентами. Ежегодно его талантливые выпускники пополняют состав ансамбля «Бермянчек» и успешно работают в коллективе, принося с собой богатый багаж знаний.

Сегодня в ансамбле работает 26 профессиональных артистов вокальной, оркестровой и танцевальной групп.

С 2009 года художественным руководителем ансамбля стала Эльмира Кашапова. Эльмира Вафичевна 17 лет проработала солисткой Государственного ансамбля песни и танца Республики Татарстан. Придя в «Бермянчек» уже состоявшейся артисткой, она начала свой путь в ансамбле с рядовой солистки. Её опыт, сильный характер и старательность позволили ей подняться выше – сначала она стала хормейстером ансамбля, а затем коллектив выдвинул её на должность художественного руководителя. В 2013 году Указом Президента Республики Татарстан Эльмире Кашаповой было присвоено почетное звание «Заслуженный артист Республики Татарстан».

Рука об руку Эльмира Вафичевна развивала ансамбль с такими профессионалами своего дела, как хореограф и балетмейстер Григорий Сергеев, который также проработал в Государственном ансамбле песни и танца Республики Татарстан 25 лет. Он совершил поездки в этнографические экспедиции в Мамадышский район. На основе материалов этих экспедиций Григорий Григорьевич подготовил несколько ярких и самобытных хореографических постановок. Из того же ансамбля пришла в «Бермянчек» и хормейстер Эльза Шамсутдинова, которая также в свое время внесла большой вклад в становление и развитие ансамбля.

Со дня основания руководителем оркестра работал Заслуженный деятель искусств Татарстана Харис Шарипович Нигметзянов – специалист с большой буквы. Его богатый опыт стал мощным импульсом для творческого процесса ансамбля, а его непревзойденный талант и чутье в аранжировках музыкальных произведений для оркестровой группы внесли неповторимый кряшенских дух.

Время идет, сцена любит молодых, ему на смену пришел Константин Владыкин – молодой перспективный дирижер, который внес свою изюминку в ансамбль. Сегодня главным дирижером ансамбля является Эрдни Чавлинов – ученик Геннадия Макарова. Он начал работать в ансамбле ещё будучи студентом третьего курса консерватории. Эрдни Зулаевич – находка для ансамбля. Это человек-оркестр, который может играть на аутентичных инструментах – на кубызе, курае, думбре, гуслях и на клавишных. Тот факт, что Эрдни по национальности калмык, не помешало ему прочувствовать всю прелесть кряшенского фольклора. Напротив, сегодня он исполняет кряшенскую музыку именно так, чтобы она проникла в сердце каждого кряшена.



Презентация Государственного фольклорного ансамбля кряшен «Бермянчек» состоялась 2 декабря 2009 года в концертном зале Татарской государственной филармонии имени Габдуллы Тукая. Почетными гостями торжества стали заместитель Премьер-министра Татарстана – министр культуры Зиля Валеева, депутат Государственного Совета Татарстана Разиль Валеев, председатель правления Общественной организации кряшен республики Иван Егоров. Несомненно, появления Государственного ансамбля кряшен в Татарстане ждали давно. Со сцены филармонии звучали старинные напевы кряшен, аутентичная инструментальная музыка, исполнялись красивые народные танцы. Услышав знакомые мотивы, зрители просто не могли сдержать слез. В 2010 году ансамбль возглавил новый директор – Артур Владимирович Поляков. Молодой и энергичный, горящий новыми идеями и обуреваемый самыми смелыми планами, он смог поднять ансамбль на более высокий уровень. В 2016 году труд Артура Полякова был оценен руководством республики и ему было присвоено звание «Заслуженный работник культуры Республики Татарстан».

Большой вклад в развитие ансамбля внесла солистка Лиана Миронова. Будучи носительницей кряшенской культуры, она в полной мере смогла раскрыть свой творческий потенциал – в ансамбле она поставила свои небольшие программы, основанные на репертуаре её родной деревни Старое Гришкино Менделеевского района. Уникальна данная природой особенная кряшенская мелизматика Снежаны Абрамовой. В совершенстве владеет аутентичной манерой исполнения главный хормейстер ансамбля Эльвира Камалова – выпускница отделения этномузыкологии Казанской консерватории. Сегодня она продолжает научное изучение кряшенской этнической культуры, защитила кандидатскую диссертацию и является кандидатом искусствоведения.



Яркая солистка Оксана Дмитриева хоть и окончила курс академического вокала, великолепно справляется с исполнением непростых аутентичных песен. В 2017 году она была удостоена звания Заслуженной артистки Татарстана. Еще один из ярких солистов в «Бермянчек» – Александр Игнатьев. Его талант в полной мере раскрылся в ансамбле, а заметили его на конкурсе кряшенской песни «Туым Жондозы». Из молодых артисток особое место занимает и Юлия Савельева.

В 2015 году, будучи студенткой Казанской государственной консерватории, она стала победительницей республиканского конкурса «Кряшен чибяре» («Кряшенская красавица»). Стоит отметить, что Юлия является представительницей нагайбакского этноса и специалистом по нагайбакскому фольклору. Ещё одна кряшенская красавица коллектива – Регина Павлова.

Талантливая девушка с детства впитала все особенности кряшенской песни и народной культуры. Она является выпускницей кафедры народного пения Народной артистки Татарстана Венеры Ганеевой, блистает в музыкальных конкурсах и радует своим очаровательным голосом. Уникальным человеком в ансамбле является артистка оркестра Елена Григорьева. Еще будучи студенткой, она начала свой творческий путь в ансамбле народных инструментов Хариса Нигметзянова. В 2009 году пришла в «Бермянчек» и здесь проявила себя как талантливый и разносторонний артист – она великолепно играет на самых разных этнических духовых инструментах, на гуслях и кубызе, поёт и участвует в сценических постановках. В 2016 году Елене Михайловне присвоено звание «Заслуженный артист Республики Татарстан».



Заслуживает уважения многолетний труд артистов-вокалистов – Ильнара Зайнутдинова, Газинура Загидуллина, Ильнура Ахатова, Ильмира Касимова, Лилии Хафизовой. Непревзойденные кряшенские мелодии на протяжении этих десяти лет звучат со сцены благодаря таким высококлассным музыкантам, как Азат Хамидуллин, Адель Низамутдинов, Дмитрий Матвеев, Римма Бикиева, Марсель Авзалов. Большой вклад в становление и развитие ансамбля внесла танцевальная группа коллектива. Особую грацию народных кряшенских танцев зрители могут видеть в исполнении талантливых танцоров – Радика Шайхутдинова, Лейсан Адиевой, Руслана Насыйрова, Нафисы Ахмеровой, Дмитрия Тачаева, Юлии Габдрахмановой, Алмаза Тукманова и Алсу Хусаиновой. Именно они представляют зрителям народный танец, как бесценное сокровище, как театр, показывающий быт, основные занятия, традиции, события, происходящие в жизни наших предков.



# НАШИ ПРОЕКТЫ

Бермянчек

## “ПЕТРОВ ДЕНЬ”

## “РОЖДЕСТВЕНСКАЯ ЗВЕЗДА”

Ансамбль «Бермянчек» с первых лет своего существования является главным действующим лицом в организации и проведении Республиканского фестиваля кряшенской культуры «Питрау», который с большим размахом проводится ежегодно в д. Зюри Мамадышского района Республики Татарстан. Совместно с администрацией Мамадышского муниципального района, Холдинговой компанией «Ак Барс», Ассамблеей народов Татарстана и Общественной организацией кряшен Республики Татарстан, коллектив ансамбля выполняет огромную и бесценную работу по возрождению, популяризации и передачи молодому поколению образцов кряшенской этнической культуры.

Десять лет назад фестиваль «Туым жондозы» был учрежден Общественной организацией кряшен Республики Татарстан. Сегодня соучредителями конкурса-фестиваля являются Министерство культуры Республики Татарстан и Государственный фольклорный ансамбль кряшен «Бермянчек». Конкурс-фестиваль молодых исполнителей кряшенской песни «Туым Жондозы» – ставит своей целью сохранение и пропаганду лучших образцов кряшенского музыкального творчества, выявление самобытных ансамблей и солистов, исполнителей произведений народной музыки. Ежегодно в рамках конкурса-фестиваля проводится состязание солистов-вокалистов и фольклорных ансамблей в семи номинациях: «Этнический вокал», «Народный вокал», «Фольклорно-эстрадный вокал», «Фольклорный ансамбль», «Вокальный ансамбль», «Вокально-инструментальный ансамбль» и «Инструментальный ансамбль». Много лет в составе жюри открывают таланты художественный руководитель Государственного фольклорного ансамбля кряшен «Бермянчек», заслуженная артистка Татарстана Эльмира Кашапова и научный сотрудник Центра развития традиционной культуры Министерства культуры республики, главный хормейстер ансамбля «Бермянчек» Эльвира Камалова – обладательница первого гран-при конкурса «Туым жондозы».



# “ВЕРБИЦЫ САД”

Республиканский православный фестиваль культуры кряшен «Бәрмәнчек бакчасы» – «Вербицы сад» проводится с 2016 года Государственным фольклорным ансамблем кряшен «Бермянчек» при поддержке Министерства культуры Республики Татарстан, Общественной организацией кряшен Татарстана по благословению митрополита Казанского и Татарстанского Феофана.

Республиканский православный фестиваль культуры кряшен «Бәрмәнчек бакчасы» – «Вербицы сад» проводится с 2016 года Государственным фольклорным ансамблем кряшен «Бермянчек» при поддержке Министерства культуры Республики Татарстан, Общественной организацией кряшен Татарстана по благословению митрополита Казанского и Татарстанского Феофана.

Главная цель фестиваля – содействие духовно-нравственному воспитанию детей и молодежи, их приобщение к ценностям музыкально-поэтического, декоративно-прикладного творчества в религиозном и этническом искусстве; сохранение и развитие церковно-певческих, поэтических, языковых традиций кряшен Республики Татарстан.

Масштабен охват участников фестиваля «Вербицы сад»: за два года в фестивале приняли участие солисты и коллективы не только из городов и районов Татарстана, но и из регионов России – Челябинской, Самарской, Кировской областей.

# НАШИ ДОСТИЖЕНИЯ

Ансамбль «Бермянчек» является дипломантом и лауреатом многих региональных, всероссийских, международных конкурсов и фестивалей. За десятилетнюю историю ансамбля коллектив получил немало Почетных грамот и Благодарственных писем.

**2009**

ДИПЛОМ ЗА УЧАСТИЕ В XXIV РЕСПУБЛИКАНСКОМ ПРАЗДНИКЕ НАРОДНОГО ТВОРЧЕСТВА «ИГРАЙ, ГАРМОНЬ – РАДУГА ТАЛАНТОВ ТАТАРСТАНА»

2010

ЛАУРЕАТ ФЕСТИВАЛЯ МИРОВЫХ КУЛЬТУР «АЛТЫН МАЙДАН»
ДИПЛОМ II СТЕПЕНИ В НОМИНАЦИИ «ВОКАЛЬНЫЙ АНСАМБЛЬ» ФЕСТИВАЛЯ МИРОВЫХ КУЛЬТУР «АЛТЫН МАЙДАН»
ДИПЛОМ II СТЕПЕНИ В НОМИНАЦИИ «ИНСТРУМЕНТАЛЬНЫЙ АНСАМБЛЬ» ФЕСТИВАЛЯ МИРОВЫХ КУЛЬТУР «АЛТЫН МАЙДАН»
ДИПЛОМ II СТЕПЕНИ В НОМИНАЦИИ «ФОЛЬКЛОРНЫЙ АНСАМБЛЬ» ФЕСТИВАЛЯ МИРОВЫХ КУЛЬТУР «АЛТЫН МАЙДАН»
БЛАГОДАРСТВЕННОЕ ПИСЬМО ГОРОДСКОЙ НАЦИОНАЛЬНО-КУЛЬТУРНОЙ ОБЩЕСТВЕННОЙ ОРГАНИЗАЦИИ САНКТ-ПЕТЕРБУРГСКОГО ФИЛИАЛА ВСЕРОССИЙСКОГО ОБЩЕСТВЕННОГО ФОНДА «ТАТАРСКАЯ СЕМЬЯ»

**2011**

ДИПЛОМ ЗА УЧАСТИЕ В МЕЖДУНАРОДНОМ ФЕСТИВАЛЕ «КАЗАЧЬЯ СТАНИЦА 2011» Г МОСКВА
ДИПЛОМ УЧАСТНИКА ФЕСТИВАЛЯ НАЦИОНАЛЬНЫХ КУЛЬТУР «НИЖНИЙ НОВГОРОД – СТОЛИЦА НАРОДОВ ПОВОЛЖЬЯ»
ДИПЛОМ ЗА АКТИВНОЕ УЧАСТИЕ В XX ЮБИЛЕЙНОМ ПРАЗДНИКЕ «ПИТРАУ» Г. НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
ДИПЛОМ ЗА УЧАСТИЕ В ФЕСТИВАЛЕ НАГАЙБАКСКОЙ КУЛЬТУРЫ «АРЫУМЫ СЫЗ, ТУГАННАР», НАГАЙБАКСКИЙ РАЙОН, ЧЕЛЯБИНСКАЯ ОБЛАСТЬ
ДИПЛОМ ЗА УЧАСТИЕ В МЕЖДУНАРОДНОМ ФЕСТИВАЛЕ ТАНЦА «ДУКАТ ФЕСТ» БОСНИЯ И ГЕРЦЕГОВИНА, Г. БАНЯ-ЛУКА
ДИПЛОМ ЗА УЧАСТИЕ В ЕЖЕГОДНОМ РОЖДЕСТВЕНСКОМ ФЕСТИВАЛЕ «СВЕТ ВИФЛЕЕМСКОЙ ЗВЕЗДЫ» Г. ЗЕЛЕНОДОЛЬСК

**2012**

ДИПЛОМ УЧАСТНИКА ФЕСТИВАЛЯ НАЦИОНАЛЬНЫХ КУЛЬТУР «НИЖНИЙ НОВГОРОД – СТОЛИЦА НАРОДОВ ПОВОЛЖЬЯ»
ДИПЛОМ ЗА УЧАСТИЕ В XIII МЕЖДУНАРОДНОМ ФОЛЬКЛОРНОМ ФЕСТИВАЛЕ В ТУРЦИИ Г. СТАМБУЛ
ДИПЛОМ ЗА УЧАСТИЕ В ЕЖЕГОДНОМ РОЖДЕСТВЕНСКОМ ФЕСТИВАЛЕ «СВЕТ ВИФЛЕЕМСКОЙ ЗВЕЗДЫ»
БЛАГОДАРСТВЕННОЕ ПИСЬМО ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РТ

**2013**
ДИПЛОМ ЛАУРЕАТА ПРАВОСЛАВНОГО АВРААМИЕВСКОГО ФЕСТИВАЛЯ
ПОЧЕТНАЯ ГРАМОТА ОТ КОМАНДИРА ВОЙСКОВОЙ ЧАСТИ 5598 ПОЛКОВНИКА ФИЛИППОВА Д.М.
БЛАГОДАРСТВЕННОЕ ПИСЬМО ОТ МЕЖДУНАРОДНОЙ ВЫСТАВКИ-ЯРМАРКИ НАРОДНЫХ ПРОМЫСЛОВ И РЕМЕСЕЛ СНГ «КАЗАНСКАЯ ЧАША»

**2014**
ЛАУРЕАТ VII МЕЖДУНАРОДНОГО ФОЛЬКЛОРНОГО КОНКУРСА «ГРАН-ПРИ ИНТЕРФОЛК»
ДИПЛОМ ЗА УЧАСТИЕ В VII МЕЖДУНАРОДНОМ ФОЛЬКЛОРНОМ ФЕСТИВАЛЕ «ИНТЕРФОЛК В РОССИИ»
ДИПЛОМ УЧАСТНИКА ГАЛА-КОНЦЕРТА РЕСПУБЛИКАНСКОГО ЭТНОКУЛЬТУРНОГО ФЕСТИВАЛЯ «НАШ ДОМ – ТАТАРСТАН»
ПОЧЕТНАЯ ГРАМОТА II АВРААМИЕВСКОГО ФЕСТИВАЛЯ «ЦЕРКОВЬ И КАЗАЧЕСТВО. МЫ – СВЯЩЕННАЯ РУСЬ, МЫ – ОПОРА ДЕРЖАВЫ»
БЛАГОДАРСТВЕННОЕ ПИСЬМО НАСТОЯТЕЛЯ СВЯТО-ТРОИЦКОГО ХРАМА – СВЯЩЕННИКА ДИМИТРИЯ СИЗОВА

**2015**
ДИПЛОМ ЛАУРЕАТА РЕСПУБЛИКАНСКОГО ЭТНОКУЛЬТУРНОГО ФЕСТИВАЛЯ «НАШ ДОМ – ТАТАРСТАН»
БЛАГОДАРСТВЕННОЕ ПИСЬМО ПРЕДСЕДАТЕЛЯ МЕЖДУНАРОДНОГО ОБЪЕДИНЕНИЯ ПРОФСОЮЗОВ РАБОТНИКОВ ТРАНСПОРТА И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА ШУРИКОВА А.Л.
БЛАГОДАРСТВЕННОЕ ПИСЬМО РУССКОЙ ПРАВОСЛАВНОЙ ЦЕРКВИ
БЛАГОДАРСТВЕННОЕ ПИСЬМО ОБЩЕСТВЕННОЙ ОРГАНИЗАЦИИ КРЯШЕН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**2016**
БЛАГОДАРСТВЕННОЕ ПИСЬМО АССАМБЛЕИ НАРОДОВ ТАТАРСТАНА И ДОМА ДРУЖБЫ НАРОДОВ ТАТАРСТАНА
ПОЧЕТНАЯ ГРАМОТА АССАМБЛЕИ НАРОДОВ ТАТАРСТАНА

**2017**
ДИПЛОМ ЗА УЧАСТИЕ В 45-М МЕЖДУНАРОДНОМ ФЕСТИВАЛЕ БОЛГАРИИ Г. БУРГАС
ДИПЛОМ УЧАСТНИКА ТВОРЧЕСКОЙ ПРОГРАММЫ МЕЖДУНАРОДНОЙ НАУЧНО-ПРАКТИЧЕСКОЙ КОНФЕРЕНЦИИ «ТРАДИЦИОННАЯ МУЗЫКАЛЬНАЯ КУЛЬТУРА НАРОДОВ ПОВОЛЖЬЯ И ПРИУРАЛЬЯ: ТЕОРИЯ И ПРАКТИКА»
БЛАГОДАРСТВЕННОЕ ПИСЬМО ОБЩЕСТВЕННОЙ ОРГАНИЗАЦИИ ТАТАРСКОЙ НАЦИОНАЛЬНО-КУЛЬТУРНОЙ АВТОНОМИИ НОВОСИБИРСКОЙ ОБЛАСТИ, ГБУК НСО «НОВОСИБИРСКОЙ ОБЛАСТНОЙ ТАТАРСКОГО КУЛЬТУРНОГО ЦЕНТРА»
БЛАГОДАРСТВЕННОЕ ПИСЬМО ТАТАРСТАНСКОЙ МИТРОПОЛИИ КАЗАНСКОЙ ЕПАРХИИ



# РЕПЕРТУАР АНСАМБЛЯ «Бермянчек»

На сегодняшний день в репертуаре ансамбля насчитывается более 150 кряшенских народных песен, собранных в разных регионах Республики Татарстан и за ее пределами, более 30 танцев, поставленных в традиционном стиле. Оркестр ансамбля исполняет старинную этническую музыку кряшен на традиционных музыкальных инструментах.
Творчество Государственного фольклорного ансамбля кряшен «Бермянчек» пронизано идеей сохранения самобытности, национальных традиций кряшен. Главная задача ансамбля «Бермянчек» – через единство музыки, песен и танцев донести до зрителей национальный дух, колорит, быт, душевное тепло и задор кряшенского народа, показать особенности и отличия в фольклорном материале различных территориальных групп кряшен.

Самую первую программу-презентацию Государственного фольклорного ансамбля «Бермянчек» подготовил режиссер-педагог Казанского государственного института культуры Раушан Шарипов вместе с актрисой Аграфеной Васильевой. В программу концерта вошли песни и танцы, собранные в Заинском, Мамадышском, Пестречинском районах Республики Татарстан и в Нагайбакском районе Челябинской области.

# ГОСУДАРСТВЕННЫЙ ФОЛЬКЛОРНЫЙ АНСАМБЛЬ КРЯШЕН



На сегодняшний день в репертуаре ансамбля насчитывается более 150 кряшенских народных песен, собранных в разных регионах Республики Татарстан и за ее пределами, более 30 танцев, поставленных в традиционном стиле. Оркестр ансамбля исполняет старинную этническую музыку кряшен на традиционных музыкальных инструментах.

Творчество Государственного фольклорного ансамбля кряшен «Бермянчек» пронизано идеей сохранения самобытности, национальных традиций кряшен. Главная задача ансамбля «Бермянчек» – через единство музыки, песен и танцев донести до зрителей национальный дух, колорит, быт, душевное тепло и задор кряшенского народа, показать особенности и отличия в фольклорном материале различных территориальных групп кряшен.

20 ноября 2010 года в концертном зале Татарской государственной филармонии имени Габдуллы Тукая в рамках открытия нового сезона на суд зрителей была представлена программа, поставленная по мотивам старинного календарного праздника «Нардуган». Нардуган – это древний языческий праздник зимнего солнцестояния, с ряжеными, песнями и танцами, а также святочными гаданиями. Автором программы стала Аграфена Васильева. В рамках концерта были исполнены самобытные песни и танцы, собранные в разных регионах Республики Татарстан, в полной мере раскрывающие особенность этого древнего праздника.

31 октября 2011 года на сцене Татарского государственного Академического театра имени Галиасгара Камала была представлена концертная программа «Изге Пыкрау» («Святой Покров»). Программу поставил Народный артист Татарстана, Заслуженный артист России Ильдар Хайруллин. Концерт представил собой театрализованное действие, куда вошли традиционные гостевые песни, народные танцы кряшен, раскрывающие в полной мере обычаи и традиции православного праздника Покрова Пресвятой Богородицы.

В 2012 году ансамблем была создана новая уникальная программа, посвященная одному из важнейших кряшенских, православных праздников Троице, которая отмечается на пятидесятый день после Пасхи. В программу были выбраны самобытные обрядовые песни кряшен, благодаря которым был ярко и глубоко представлен старинный календарный обряд «Троица».

В этом же году была подготовлена программа «Туым Жондозы» («Рождественская звезда»). Её автором стал фольклорист Геннадий Макаров. В неё вошли старинные обрядовые гостевые песни и танцы с ряжеными, собранные в Менделеевском, Тукаевском, Лаишевском районах Республики Татарстан.

К своему 5-летию ансамбль подготовил на суд зрителей еще одну интереснейшую программу «Үткәннәргә сәяхәт» («Путешествие в прошлое»). В основе программы, составленной художественным руководителем ансамбля Эльмирой Кашаповой, была заложена идея преемственности традиций – передачи богатого исторического наследия от старшего поколения к младшему. В главной роли здесь выступил Народный артист Татарстана, Заслуженный артист России – Николай Дунаев. Программа состояла из 5 разделов и вобрала в себя традиционную культуру кряшен Лаишевского, Пестречинского, Менделеевского, Мамадышского и Кайбицкого районов Республики Татарстан, отражающую уникальные особенности фольклора каждой из этих локальных групп.

К 70-летию Победы в Великой Отечественной войне в 2015 году ансамблем «Бермянчек» была подготовлена театрализованная композиция «Баллада о матери», куда вошли песни и танцы военных лет. С этой программой ансамбль выезжал в гастрольный тур по городам и районам Татарстана, где проводились праздничные концерты для ветеранов Великой Отечественной войны и тружеников тыла.

Особенно яркой и запоминающейся для зрителей стала новая концертная программа 2017 года под названием «Без Туганайлар». 2017 год замечателен тем, что в этом году кряшены Челябинской области, которые теперь имеют самоназвание «нагайбаки», отметили 175 лет со дня основания нагайбакских казачьих поселений на Южном Урале. Этому событию было приурочено первое отделение концерта, куда вошел самобытный фольклор казаков-нагайбаков. Во втором отделении артисты ансамбля «Бермянчек» представили песенные и танцевальные номера, собранные во время фольклорных экспедиций в деревнях Кайбицкого района (частушки деревни Хозесаново – «Хужа Хасан такмаклары»), а также уникальный танец с самоварной трубой из деревни Ташкирмень Лаишевского района. Зрители смогли услышать старинные кряшенские песни в рок и фолк-обработке, совместно с рок-группой «Хмельная ворга» (г. Казань). Здесь же был презентован номер с использованием шотландской волынки, которая очень запомнилась зрителям. Режиссером концерта снова выступил Народный артист Татарстана, Заслуженный артист России Ильдар Хайруллин, автором идеи и сорежиссером программы стала Заслуженная артистка Татарстана, художественный руководитель ансамбля Эльмира Кашапова.

Государственный фольклорный ансамбль кряшен «Бермянчек» неоднократно принимал участие в съемках телевизионных проектов. Так, в 2012 году для телепередачи «Аулак өй» на республиканском канале «ТНВ» были сняты программы «Бермянчек» («Вербное воскресение»), «Олы көн» («Пасха»), «Тройсын» («Троица»). В 2013 и 2016 годах ансамбль принял участие в съемках легендарной программы на российском телевидении «Играй, гармонь, любимая!» с Анастасией Заволокиной, которая транслируется на Первом канале. А в 2014 году состоялась съемка в телевизионной программе «Каравай» на канале «ТНВ», где ансамблем «Бермянчек» был показан обряд «Пыкрау» («Покров день»).





# Бәрмәнчек

## “Бәрмәнчек, һәрчак балкы, сoклансын дөнья халкы!”

Бәрмәнчек – тал агачы чәчәге; яз көне тал ботакларында бөреләр, йомшак йонлы тал “песиләре” барлыкка килә. Тал “песие” – христиан традицияләрендә төп православ бәйрәмнәрнең берсе булган “Бәрмәнчек атнасы”ның атрибуты да. Керәшеннәр “Олы көн” (“Пасха”) бәйрәменә бер атна кала бәрмәнчекләр алып, аларны чиркәүдә изгеләндереп, ел буе тәре алдында саклыйлар. Гомумән, борынгы мәҗүсилектән үк калган, күбрәк славян халыкларында билгеле булган бу йоланың мәгънәсе болай аңлатыла. Озын кыштан соң, иң беренче булып уянган әлеге агачны халык зур көчкә ия дип саный. Шуның өчен, иртә яшәргән, яфрак ярган чәчәкле тал чыбыклары белән суккалап алу, аның яшәрү һәм яшәү көчен кешеләргә, мал-туарларга бирәсе килү теләге белән эшләнә булса кирәк. Тал “песие” уңдырышлылык, сәламәтлек, шатлык гәүдәләндерә, тормышның өзлексез һәм даими торышының символы булып тора.



# А Н С А М Б Л Ь   Т А Р И Х Ы

2008 елның февралендә Татарстан Республикасы керәшеннәренең иҗтимагый оешмасы тәкъдиме, Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев, Республика хөкүмәте һәм Мәдәният министрлыгы ярдәме белән керәшеннәрнең "Бәрмәнчек" дәүләт фольклор ансамбле оештырыла.
Әмма ансамбльнең чишмә башы 2002 елга барып тоташа, ул вакытта Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты базасында "Бәрмәнчек" керәшен яшьләр фольклор ансамбле оештырыла. Ансамбльдә, беренчеләрдән булып, мәдәният университетының милли сәнгать факультеты студентлары Оксана Дмитриева, Сергей Гладков, Снежана Абрамова, Алексей Савельев, Римма Никитина, Лиана Миронова, шулай ук, Нәҗип Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе студентлары Вера Васильева һәм Светлана Матвеева катнашалар. Ансамбльнең сәнгать җитәкчесе – танылган фольклорчы, этномузыколог, сәнгать фәннәре кандидаты Геннадий Макаров.
Алты елдан соң, республика җитәкчелеге Татарстан Министрлар Кабинетының 2008 елның 11 февралендәге 73 нче номерлы Карары белән, "Керәшеннәрнең "Бәрмәнчек" дәүләт фольклор ансамбле" Татарстан Республикасы Дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе төзү турында карар чыгара. Ансамбльнең директоры итеп Татарстаннын атказанган мәдәният хезмәткәре Геннадий Максимов билгеләнә.

Бәрмәнчек – тал агачы чәчәге; яз көне тал ботакларында бөреләр, йомшак йонлы тал "песиләре" барлыкка килә. Тал "песие" – христиан традицияләрендә төп православ бәйрәмнәрнең берсе булган "Бәрмәнчек атнасы"ның атрибуты да. Керәшеннәр "Олы көн" ("Пасха") бәйрәменә бер атна кала бәрмәнчекләр алып, аларны чиркәүдә изгеләндереп, ел буе тәре алдында саклыйлар. Гомумән, борынгы мәҗүсилектән үк калган, күбрәк славян халыкларында билгеле булган бу йоланың мәгънәсе болай аңлатыла. Озын кыштан соң, иң беренче булып уянган әлеге агачны халык зур көчкә ия дип саный. Шуның өчен, иртә яшәргән, яфрак ярган чәчәкле тал чыбыклары белән суккалап алу, аның яшәру һәм яшәү көчен кешеләргә, мал-туарларга бирәсе килү теләге белән эшләнә булса кирәк. Тал "песие" уңдырышлылык, сәламәтлек, шатлык гәүдәләндерә, тормышның өзлексез һәм даими торышының символы булып тора.

Бу вакытка Геннадий Макаров ансамбленең төп составын әзерләгән була инде. Яңа оешкан ансамбльгә, шулай ук, республиканың башка коллективларыннан тәҗрибәле артистлар да чакырыла. Геннадий Михайлович ансамбльнең чишмә башында гына түгел, ә унъеллык дәверендә коллективның һәр вәкиле өчен таяну ноктасы да булып тора, дип әйтергә мөмкин. Аның бай тәҗрибәсе һәм һөнәри сиземлелеге аркасында, "Бәрмәнчек" кыска вакыт эчендә Татарстанда гына түгел, бөтен Россия буенча дан казанды. "Бәрмәнчек" ансамбленең бүгенге репертуары – Геннадий Макаровның күпьеллык этнографик экспедицияләре нәтиҗәсе, ул шактый еллар буе керәшеннәрнең территориаль төркемнәренең үзенчәлекле һәм төрле планлы үрнәкләрен туплады. Шунысы куанычлы, Геннадий Макаров һәм аның студентлары тарафыннан әлеге эш бүгенге көндә дә дәвам итә. Ел саен аның талантлы шәкертләре "Бәрмәнчек" ансамбле составын тулыландыра, үзләре белән бай белем алып килеп, коллективта уңышлы иҗат итә. Бүген ансамбльдә вокал, бию һәм оркестр группаларында 26 профессиональ артист эшли.
2009 елда ансамбльнең сәнгать җитәкчесе итеп Эльмира Кашапова билгеләнде. Эльмира Вафичевна 17 ел Татарстан Республикасы дәүләт җыр һәм бию ансамбле солисткасы булып эшләгән. "Бәрмәнчек"кә тәҗрибәле артист буларак килсә дә, ансамбльдә "рядовой" солистка булып эш башлый. Белеме, көчле холкы һәм тырышлыгы аңа югары күтәрелергә мөмкинлек бирде – Эльмира Вафичевна башта ансамбльнең хормейстеры булса, соңрак коллектив аны сәнгать җитәкчесе вазыйфасына тәкъдим итте. 2013 елда Эльмира Кашаповага Татарстан Республикасы Президенты Указы белән "Татарстан Республикасының атказанган артисты" дигән мактаулы исем бирелде.



Эльмира Вафичевна "Бәрмәнчек"не, 25 ел дәвамында Татарстан Республикасы дәүләт җыр һәм бию ансамблендә эшләгән, хореограф һәм балетмейстер Григорий Сергеев кебек профессионаллар белән бергә үстерде. Григорий Григорьевич Мамадыш районына этнографик экспедицияләргә барды һәм әлеге төбәк керәшеннәренең биюләрен сәхнәгә куйды. Дәүләт җыр һәм бию ансамбленнән "Бәрмәнчек"кә килгән хормейстер Эльза Шәмсетдинова да үз вакытында коллективны үстерүгә зур өлеш кертkән белгеч.

"Бәрмәнчек" оешкан көннәрдән үк ансамбльгә сәнгать фәннәре кандидаты, Санкт-Петербург шәһәренең Россия сәнгать институты фольклор секторының өлкән фәнни хезмәткәре Наилә Юнисовна Әлмиева зур ярдәм күрсәтте. Ул 1978 елдан экспедицияләрдә йөреп, керәшен җырларын яздыра башлый. Шул вакыттан бирле, бөртекләп, диярлек, бик күп уникаль язма җыйды. "Керәшен җырларын башкару бик катлаулы, ләкин бозу шундый җиңел", – дип кабатлый Наилә Юнисовна. Аларның ничек җырлавын аңларга кирәк, фольклор турында белемле булу зарур. Наилә Әлмиева, үз чиратында, этник җырларны дөрес башкару буенча ансамбльгә һәрвакыт ярдәм итәргә әзер. Ул даими рәвештә "Бәрмәнчек" солистлары өчен керәшен җыры буенча лекцияләр, семинарлар, мастер-класслар үткәрә. Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, Наилә Юнисовна "Керәшен-татарларының көйләре" дип исемләргән китап сериясенең авторы булып тора. Галимә аларда керәшеннәрнең төрле территориаль төркемнәренең җыр фольклорын тәкъдим итә. Питрәч һәм Мәлки (Кайбыч) керәшеннәрнең музыкаль мирасын үз эченә алган ике том инде дөнья күрде. Хәзер Мамадыш, Алабуга һәм Минзәлә керәшеннәренең музыка мәдәнияте буенча тагын өчен том нәшер итәлергә әзерләнә. Әлеге басмалар керәшеннәрнең борынгы көйләренең төрлелеген күрсәтү максаты белән әзерләнә: анда кунак каршылау, табын арты, туй, рекрут, түгәрәк уен көйләре урын алган. Бу китаплар музыкаль-этнографик фән өчен дә, Татарстан һәм Россия мәдәнияте өчен дә зур байлык. "Бәрмәнчек" ансамбле өчен дә бәяләп бетергесез материал.

# КЕРӘШЕННӘРНЕҢ ДӘҮЛӘТ ФОЛЬКЛОР АНСАМБЛЕ

Ансамбльгә нигез салынган көннән үк оркестр җитәкчесе булып Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Харис Шәрипович Нигъмәтҗанов эшләде. Аның бай тәҗрибәсе ансамбльнең иҗаты өчен көчле этәргеч булды, ә таланты һәм музыка әсәрләренең аранжировкаларындагы сизгерлеге оркестр төркеменә  кабатланмас керәшен рухы кертте. Вакыт уза, сәхнә яшьләрне ярата, аңа алмашка Константин Владыкин килде. Ул ансамбльгә үзенә генә хас үзенчәлек керткән, яшь, перспективалы дирижер. Бүген ансамбльнең баш дирижеры – Эрдни Чавлинов – Геннадий Макаров укучысы. "Бәрмәнчек"тә консерваториянең өченче курсында укыганда ук эшли башлады. Эрдни – ансамбль өчен зур табыш. Аутентик уен коралларында – кубызда да, дубрада да, гөсләдә дә һәм клавишалыларда да уйный ала торган яхшы музыкант. Милләте буенча калмык булса да, керәшен фольклорын бөтен нечкәлекләренә кадәр тоя. Керәшен музыкасын һәрбер керәшен йөрәгенә үтеп керердәй итеп, яратып башкара.

"Бәрмәнчек" дәүләт фольклор ансамблен тәкъдим итү 2009 елның 2 декабрендә Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең концертлар залында узды.  Татарстан Премьер-министры урынбасары – мәдәният министры Зилә Вәлиева, Татарстан Дәүләт Советы депутаты Разил Вәлиев, Республика керәшеннәренең иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисе Иван Егоров тантананың мәртәбәле кунаклары булды. Керәшеннәрнең дәүләт ансамбле барлыкка килүе Татарстанда, һичшиксез, күптән көтелгән иде. Филармония сәхнәсеннән керәшеннәрнең борынгы җырулары яңгырады. Таныш мотивларны ишетеп, тамашачы күз яшьләрен тыя алмады.

2010 елда ансамбльне яңа директор – Артур Владимирович Поляков җитәкләде. Яңа идеяләр белән янып торучы, киләчәккә кыю планнары булган яшь һәм энергияле җитәкче ансамбльне тагын да югарырак дәрәҗәгә күтәрә алды. 2016 елда Артур Поляковка, хезмәте республика җитәкчелеге тарафыннан югары бәяләнеп, "Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре" исеме бирелде.



Ансамбль үсешенә солистка Лиана Миронова да зур өлеш кертте. Лиананың иҗади таланты тулысы белән ансамбльдә ачылды. Ул концерт сезоннарының берсендә туган авылы Иске Гришкино репертуарына нигезләнгән программаны сәхнәгә куйды. Беренче көннән үк ансамбльдә булган Снежана Абрамованы да билгеләп узмый булмый. Анда табигать биргән, берәүдә дә, беркайда да кабатланмас керәшен мелизматикасы бар. Казан консерваториясенең этномузыкология бүлеген тәмамлаган ансамбльнең баш хормейстеры Эльвира Камалованың да камил аутентик башкару манерасы бар. Бүген ул керәшен этник мәдәниятен өйрәнүне дәвам итә, кандидатлык диссертациясен яклады һәм сәнгать фәннәре кандидаты дәрәҗәсен алды.



Артист-вокалчылар – Илнар Зәйнетдинов, Газинур Заһидуллин, Илнар Әхәтов, Илмир Касыймовның күп еллык хезмәтләре дә хөрмәткә лаек. Шушы ун ел дәверендә сәхнәдән күңел кылларын тибрәтүче керәшен көйләре Азат Хәмидуллин, Адель Низаметдинов, Дмитрий Матвеев, Римма Бикиева, Марсель Авзалов кебек югары классны музыкантлар башкаруында яңгырый. Ансамбльнең оешуына һәм үсешенә коллективның бию төркеме зур өлеш кертте. Керәшен халык биюләренең аерым үзенчәлекләрен тамашачылар талантлы биючеләр Радик Шәйхетдинов, Ләйсән Әдиева, Руслан Насыйров, Нәфисә Әхмәрова, Дмитрий Тачаев, Юлия Габдрахманова, Алмаз Токманов һәм Алсу Хөсәенова башкаруында күрә алалар. Нәкъ менә алар тамашачыларга ата-бабаларыбыз тормышында барган вакыйгаларны – тормыш-көнкүрешләрен, төп шөгыльләрен, гореф-гадәтләрен күрсәтә торган, бәяләп бетергесез хәзинә буларак, халык биюләрен тәкъдим итә.

Унъеллык иҗаты дәверендә коллектив шатлыклы да, кайгылы да мизгелләр кичерде. Кызганычка каршы, 2011 елда ансамбльнең талантлы солисты Диана Мишкина фаҗигале төстә вафат булды. Ул тормышны яратучы, талантлы артистка иде, аңа уңышлы иҗади киләчәк юрадылар, ансамбль зур өметләр баглады. 2013 елда биюче Камил Байбиков та фаҗигале төстә вафат булды. Бу югалтуларны коллектив әле дә авыр кичерә.

Күренекле солистка Оксана Дмитриева, академик вокал курсын тәмамласа да, катлаулы аутентик җырларны да бик яхшы башкара. 2017 елда ул "Татарстанның атказанган артисткасы" исеменә лаек булды. "Бәрмәнчек" ансамбленең якты солистларының тагын берсе – Александр Игнатьев. "Туым жондозы" керәшен җыры конкурсында җиңүче булган егетнең таланты тулысынча ансамбльдә ачылды. Яшь артистлардан Юлия Савельева иҗаты да ансамбльдә аерым урын алып тора. 2015 елда ул, Казан дәүләт консерваториясе студенты буларак, "Кряшен чибәре" республика конкурсында катнашып, җиңүче булды. Әйтергә кирәк, Юлия нагайбәк этносы вәкиле һәм нагайбәк фольклоры белгече. Коллективның тагын бер керәшен чибәре – Регина Павлова. Талантлы кыз балачактан ук керәшен җырларын һәм халык мәдәниятен күңеленә сеңдереп үскән. Татарстанның халык артисткасы Винера Ганиеваның шәкерте, төрле бәйгеләрдә җиңү яулап, тамашачыны үзенең искиткеч тавышы белән шатландыра. Ансамбльнең кабатланмас кешесе дип, шулай ук, оркестр артисты Елена Григорьеваны да атарга була. Ул, әле студент чагында ук, Харис Нигъмәтҗановның халык уен кораллары ансамблендә иҗат юлын башлап җибәрә. 2009 елда "Бәрмәнчек"кә килде, бирелә үзен талантлы һәм күпкырлы артист буларак күрсәтте – төрле инструментларда уйный, җырлый һәм сәхнә куелышларында катнаша. 2016 елда Елена Михайловнага "Татарстан Республикасының атказанган артисты" исеме бирелде.

# БЕЗНЕҢ ПРОЕКТЛАР

Бәрмәнчек

## "ПИТРАУ"

Мамадыш районының Җөри авылында ел саен зур колач белән уздырыла торган "Питрау" керәшен мәдәнияте республика фестивален оештыру һәм үткәрүдә "Бәрмәнчек" ансамбле төп көч куючыларның берсе. Ансамбль коллективы Мамадыш муниципаль районы администрациясе, "Ак Барс" Холдинг" компаниясе, Татарстан Халыклары Ассамблеясе һәм Татарстан Республикасы керәшеннәренең иҗтимагый оешмасы белән берлектә яшь буынга керәшен этник мәдәнияте үрнәкләрен торгызу, популярлаштыру һәм тапшыру буенча зур һәм бәһасез эш башкара.

## "ТУЫМ ЖОНДОЗЫ"

Ун ел элек "Туым жондозы" керәшен җыруларын яшь башкаручылар республика конкурс-фестивале Татарстан Республикасы керәшеннәренең иҗтимагый оешмасы тарафыннан оештырылган иде. Берничә елдан фестивальне гамәлгә куючылар исемлегенә керәшеннәрнең "Бәрмәнчек" дәүләт фольклор ансамбле һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы да өстәлде.

"Туым жондозы" фестивале үз өстенә керәшен музыка иҗатының иң яхшы үрнәкләрен саклап калу һәм пропагандалау, үзенчәлекле ансамбльләрне һәм солистларны, халык музыкасы әсәрләрен башкаручыларны ачыклау максатын куя. Конкурс-фестиваль кысаларында ел саен җиде номинациядә солист-вокалчылар һәм фольклор ансамбльләр ярыша: "Этник вокал", "Халык вокалы", "Фольклор-эстрада вокалы", "Фольклор ансамбле", "Вокаль ансамбле", "Вокаль-уен кораллары ансамбле" һәм "Уен кораллары ансамбле". "Бәрмәнчек" дәүләт фольклор ансамбле сәнгать җитәкчесе, Татарстанның атказанган артисты Эльмира Кашапова һәм Республика Мәдәният министрлыгының Традицион мәдәниятне үстерү үзәгенең фәнни хезмәткәре, "Бәрмәнчек" ансамбленең баш хормейстеры, "Туым жондозы" конкурсының беренче Гран-при иясе Эльвира Камалова инде күп еллар конкурсның жюри составында талантлар эзли.



## “БӘРМӘНЧЕК БАКЧАСЫ”

2016 елдан башлап “Бәрмәнчек бакчасы” Республика керәшен православ мәдәнияте фестивален Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Республика керәшен оешмасы ярдәмендә, Казан һәм Татарстан митрополиты Феофан бәхиллеге белән “Бәрмәнчек” дәүләт фольклор ансамбле уздыра.
Фестивальнең төп максаты – балаларны һәм яшьләрне рухи-әхлакый тәрбияләүгә ярдәм итү, аларны дини һәм этник сәнгатьтә музыкаль-шигъри, декоратив-гамәли иҗат кыйммәтләренә җәлеп итү; Татарстан Республикасы керәшеннәренең чиркәү җырларын, шигырь, тел традицияләрен саклау һәм үстерү.
“Бәрмәнчек бакчасы” фестиваленең масштабы зур. Ике ел эчендә фестивальдә Татарстаннан гына түгел, Россиянең башка төбәкләреннән – Чиләбе, Самара, Киров өлкәләреннән дә солистлар, коллективлар катнашты.

# БЕЗНЕҢ КАЗАНЫШЛАР

“Бәрмәнчек” ансамбле күп тапкыр төбәк, бөтенроссия, халыкара конкурслар һәм фестивальләр дипломанты һәм лауреаты булды. Ансамбльнең унъеллык тарихында коллектив күп Мактау грамоталары һәм Рәхмәт хатлары алды.

**2009 ЕЛ**
“УЙНАГЫЗ, ГАРМУННАР – ТАТАРСТАН ТАЛАНТЛАРЫ САЛАВАТ КҮПЕРЕ” XXIV РЕСПУБЛИКА ХАЛЫК ИҖАТЫ БӘЙРӘМЕНДӘ КАТНАШКАНЫ ӨЧЕН ДИПЛОМ

**2010 ЕЛ**
“АЛТЫН МӘЙДАН” БӨТЕНДӨНЬЯ МӘДӘНИЯТЕ ФЕСТИВАЛЕНДӘ ЛАУРЕАТ
“АЛТЫН МӘЙДАН” БӨТЕНДӨНЬЯ МӘДӘНИЯТЕ ФЕСТИВАЛЕНЕҢ “ВОКАЛ АНСАМБЛЕ” НОМИНАЦИЯСЕНДӘ II ДӘРӘҖӘ ДИПЛОМ
“АЛТЫН МӘЙДАН” БӨТЕНДӨНЬЯ МӘДӘНИЯТЕ ФЕСТИВАЛЕНЕҢ “ИНСТРУМЕНТАЛЬ АНСАМБЛЬ” НОМИНАЦИЯСЕНДӘ II ДӘРӘҖӘ ДИПЛОМ
“АЛТЫН МӘЙДАН” ДӨНЬЯКҮЛӘМ МӘДӘНИЯТЛӘР ФЕСТИВАЛЕНЕҢ “ФОЛЬКЛОР АНСАМБЛЕ” НОМИНАЦИЯСЕНДӘ II ДӘРӘҖӘ ДИПЛОМ
“ТАТАР ГАИЛӘСЕ” БӨТЕНРОССИЯ ИҖТИМАГЫЙ ФОНДЫНЫҢ САНКТ-ПЕТЕРБУРГ ФИЛИАЛЫ ШӘҺӘР МИЛЛИ-МӘДӘНИ ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАСЫНЫҢ РӘХМӘТ ХАТЫ

**2014 ЕЛ**
МӘСКӘҮ ШӘҺӘРЕНДӘ “КАЗАЧЬЯ СТАНИЦА 2011” ХАЛЫКАРА ФЕСТИВАЛЕНДӘ КАТНАШКАНЫ ӨЧЕН ДИПЛОМ
“ТҮБӘН НОВГОРОД – ИДЕЛ БУЕ ХАЛЫКЛАРЫ БАШКАЛАСЫ” МИЛЛИ МӘДӘНИЯТЛӘР ФЕСТИВАЛЕНДӘ КАТНАШУЧЫ ДИПЛОМЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕНЕҢ “ПИТРАУ” XX ЮБИЛЕЙ БӘЙРӘМЕНДӘ АКТИВ КАТНАШКАНЫ ӨЧЕН ДИПЛОМ
“АРЫУМЫ СЫЗ, ТУГАННАР” НАГАЙБАК МӘДӘНИЯТЕ ФЕСТИВАЛЕНДӘ КАТНАШКАНЫ ӨЧЕН ДИПЛОМ, (ЧИЛӘБЕ ӨЛКӘСЕ, НАГАЙБАК РАЙОНЫ)
БОСНИЯ ҺӘМ ГЕРЦЕГОВИНА “ДУКАТ ФЕСТ” ХАЛЫКАРА БИЮ ФЕСТИВАЛЕНДӘ КАТНАШКАНЫ ӨЧЕН ДИПЛОМ, (БАНЯ-ЛУКА ШӘҺӘРЕ)
“ВИФЛЕЕМ ЙОЛДЫЗЫ ЯКТЫСЫ” ДИП ИСЕМЛӘНГӘН, ЕЛ САЕН УТКӘРЕЛӘ ТОРГАН ТУЫМ ФЕСТИВАЛЕНДӘ КАТНАШКАНЫ ӨЧЕН ДИПЛОМ (ЯШЕЛ ҮЗӘН ШӘҺӘРЕ)

**2012 ЕЛ**
“ТҮБӘН НОВГОРОД – ИДЕЛ БУЕ ХАЛЫКЛАРЫ БАШКАЛАСЫ” МИЛЛИ МӘДӘНИЯТЛӘР ФЕСТИВАЛЕНДӘ КАТНАШУЧЫ ДИПЛОМЫ
ТӨРКИЯДӘ ИСТАНБУЛ ШӘҺӘРЕНДӘ XIIII ХАЛЫКАРА ФОЛЬКЛОР ФЕСТИВАЛЕНДӘ КАТНАШКАНЫ ӨЧЕН ДИПЛОМ
“ВИФЛЕЕМ ЙОЛДЫЗЫ ЯКТЫСЫ” ДИП ИСЕМЛӘНГӘН, ЕЛ САЕН УТКӘРЕЛӘ ТОРГАН ТУЫМ ФЕСТИВАЛЕНДӘ КАТНАШУЧЫ ДИПЛОМЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫНЫҢ РӘХМӘТ ХАТЫ

**2013 ЕЛ**
ИЗГЕ АВРААМИЙ ПРАВОСЛАВ ФЕСТИВАЛЕ ЛАУРЕАТЫ ДИПЛОМЫ
5598НЧЕ ХӘРБИ ЧАСТЬ КОМАНДИРЫ ПОЛКОВНИК Д. М. ФИЛИППОВНЫҢ МАКТАУ ГРАМОТАСЫ
“КАЗАНСКАЯ ЧАША” ХАЛЫКАРА ХАЛЫК ҺӨНӘРЛӘРЕ ҺӘМ КӘСЕПЛӘРЕ КҮРГӘЗМӘ-ЯРМИНКӘСЕННӘН РӘХМӘТ ХАТЫ

**2014 ЕЛ**
“ГРАН-ПРИ ИНТЕРФОЛК” VII ХАЛЫКАРА ФОЛЬКЛОР КОНКУРСЫ ЛАУРЕАТЫ
“ИНТЕРФОЛК В РОССИИ” VII ХАЛЫКАРА ФОЛЬКЛОР ФЕСТИВАЛЕНДӘ КАТНАШКАНЫ ӨЧЕН ДИПЛОМ
“БЕЗНЕҢ ЙОРТ – ТАТАРСТАН” РЕСПУБЛИКА ЭТНОМӘДӘНИ ФЕСТИВАЛЕНЕҢ ГАЛА-КОНЦЕРТЫНДА КАТНАШУЧЫ ДИПЛОМЫ
“ЦЕРКОВЬ И КАЗАЧЕСТВО. МЫ – СВЯЩЕННАЯ РУСЬ, МЫ – ОПОРА ДЕРЖАВЫ” II АВРААМИЕВ ФЕСТИВАЛЕНЕҢ МАКТАУ ГРАМОТАСЫ
ИЗГЕ НИКОЛАЙ ХРАМЫ СВЯЩЕННИГЫ ДИМИТРИЙ СИЗОВНЫҢ РӘХМӘТ ХАТЫ

**2015 ЕЛ**
“БЕЗНЕҢ ЙОРТ – ТАТАРСТАН” РЕСПУБЛИКА ЭТНОМӘДӘНИ ФЕСТИВАЛЕ ЛАУРЕАТЫ ДИПЛОМЫ
ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ ХУҖАЛЫГЫ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ ПРОФСОЮЗЫНЫҢ ХАЛЫКАРА БЕРЛӘШМӘСЕ РӘИСЕ А. Л. ШУРИКОВНЫҢ РӘХМӘТ ХАТЫ
РУС ПРАВОСЛАВ ЧИРКӘВЕНЕҢ РӘХМӘТ ХАТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КЕРӘШЕННӘРЕНЕҢ ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАСЫНЫҢ РӘХМӘТ ХАТЫ

**2016 ЕЛ**
ТАТАРСТАН ХАЛЫКЛАРЫ АССАМБЛЕЯСЕ ҺӘМ ТАТАРСТАН ХАЛЫКЛАРЫ ДУСЛЫГЫ ЙОРТЫ РӘХМӘТ ХАТЫ
ТАТАРСТАН ХАЛЫКЛАРЫ АССАМБЛЕЯСЕНЕҢ МАКТАУ ГРАМОТАСЫ

**2017 ЕЛ**
БОЛГАРИЯНЕҢ БУРГАС ШӘҺӘРЕНДӘ УЗГАН 45 НЧЕ ХАЛЫКАРА ФЕСТИВАЛЬДӘ КАТНАШКАНЫ ӨЧЕН ДИПЛОМ
“ИДЕЛ БУЕ ҺӘМ УРАЛ БУЕ ХАЛЫКЛАРЫНЫҢ ТРАДИЦИОН МУЗЫКА МӘДӘНИЯТЕ: ТЕОРИЯ ҺӘМ ПРАКТИКА” ХАЛЫКАРА ФӘННИ-ГАМӘЛИ КОНФЕРЕНЦИЯСЕНЕҢ ИҖАТ ПРОГРАММАСЫНДА КАТНАШУЧЫ ДИПЛОМЫ
НОВОСИБИРСК ӨЛКӘСЕ ТАТАР МИЛЛИ-МӘДӘНИ АВТОНОМИЯСЕ ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАСЫНЫҢ РӘХМӘТ ХАТЫ
ТАТАРСТАН МИТРОПОЛИЯСЕНЕҢ КАЗАН ЕПАРХИЯСЕ РӘХМӘТ ХАТЫ





# АНСАМБЛЬ РЕПЕРТУАРЫ

Бәрмәнчек

Бүгенге көндә ансамбль репертуарында Татарстан Республикасының төрле төбәкләрендә һәм аннан читтә җыелган 150 дән артык керәшен халык җырлары, традицион стильдә куелган 30 дан артык бию бар. Ансамбль оркестры традицион музыка уен коралларында керәшеннәрнең борынгы этник музыкасын башкара. “Бәрмәнчек” дәүләт фольклор ансамбле иҗаты керәшеннәрнең үзенчәлеген, милли традицияләрен саклау идеясе белән сугарылган. “Бәрмәнчек” ансамбленең төп бурычы – музыка, җыр һәм биюләрнең бердәмлеге аша тамашачыларга керәшен халкының милли рухын, колоритын, көнкүрешен, күңел җылысын һәм дәртен җиткерү, керәшеннәрнең төрле территориаль төркемнәренең фольклор материалындагы үзенчәлекләрне һәм аерымлыкларын күрсәтү.

“Бәрмәнчек” дәүләт фольклор ансамбленең иң беренче программа-презентациясен Казан дәүләт мәдәният институты укытучысы – режиссер-педагог Раушан Шәрипов актриса Аграфена Васильева белән бергә әзерләде. Концерт программасына Татарстан Республикасының Зәй, Мамадыш, Питрәч районнарында һәм Чиләбе өлкәсенең Нагайбак районында җыелган җырлар һәм биюләр керде.

2010 елның 20 ноябрендә Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең Концертлар залында яңа сезон ачылу кысаларында, тамашачылар хөкеменә “Нардуган” борынгы календарь бәйрәме мотивлары буенча куелган программа тәкъдим ителде. Нардуган – кышкы Кояш торышының борынгы мәҗүси бәйрәме, костюмлы, җыр-биюле, шулай ук, бага торган бәйрәм дә. Программаның авторы Аграфена Васильева булды. Концерт кысаларында, Татарстан Республикасының төрле төбәкләрендә җыелган үзенчәлекле җырлар һәм биюләр башкарылды.

Шул ук елда “Туым җондызы” программасы да (автор – Геннадий Макаров) әзерләнде. Аңа Татарстан Республикасының Менделеевск, Тукай, Лаеш районнарында җыелган борынгы йола җырулары һәм биюләре керде.
2011 елның 31 октябрендә Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры сәхнәсендә “Изге Пыкрау” концерты тәкъдим ителде. Программаны Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Илдар Хәйруллин сәхнәгә куйды. Концертта Алла Анасы Изге Кыз Марияның Бөркәве православ бәйрәмен тулысынча ачып бирүче традицион кунак җырулары, керәшен халык биюләре күрсәтелде.
2012 елда ансамбль тарафыннан керәшеннәрнең иң мөһим православ бәйрәмнәренең берсенә – Пасхадан соң илленче көнне билгеләп үтелә торган Тройсынга багышланган яңа уникаль программа төзелде. Программага керәшеннәрнең үзенчәлекле йола җырулары сайлап алынды, алар ярдәмендә “Тройсын” борынгы календарь йоласының бар яктылыгы һәм бөтен нечкәлекләре тамашачыга тәкъдим ителде.
Ансамбльнең 5 еллыгына тамашачылар хөкеменә тагын бер кызыклы “Үткәннәргә сәяхәт” программасы (режиссер – Эльмира Кашапова) әзерләнелде. Программа нигезендә традицияләрнең дәвамчанлыгы – бай тарихи мирасны өлкән буыннан кече буынга тапшыру идеясе салынган иде. Программа биш бүлектән торды һәм Татарстан Республикасының Лаеш, Питрәч, Менделеевск, Мамадыш һәм Кайбыч районнары керәшеннәренең традицион мәдәниятен үз эченә алды. Төп рольне Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Николай Дунаев башкарды.
2015 елда, Бөек Җиңүнең 70 еллыгына, “Бәрмәнчек” ансамбле сугыш чорындагы җырлар һәм биюләр тупланган “Ана турында баллада” дип исемләнгән театральләштерелгән композиция әзерләде. Ансамбль әлеге программа белән республика буенча гастрольләр оештырып, ветераннарны котлады.

2017 елда “Без Туганайлар” дип аталган яңа концерт программасы тамашачылар өчен аеруча истә калырлык булды. 2017 ел Чиләбе өлкәсе керәшеннәренең Көньяк Уралда казак-нагайбәк авылларына нигез салуларына 175 ел тулуы белән үзенчәлекле. Бу вакыйгаларны концертның беренче бүлеге тулысынча ачып бирде, анда казак-нагайбәкләрнең үзенчәлекле фольклоры тәкъдим ителде.
Икенче бүлектә “Бәрмәнчек” ансамбле артистлары Кайбыч районы авылларында фольклор экспедицияләр вакытында җыелган җыр һәм бию номерларын (Хуҗа Хәсән такмаклары), шулай ук Лаеш районының Ташкирмән авылыннан самовар торбасы белән уникаль бию тәкъдим иттеләр. Борынгы керәшен җырулары, заманына туры китереп, махсус кунаклар – “Хмельная ворга” этно-рок-фолк төркеме белән берлектә башкарылды.
Ансамбльнең сәнгать осталары – Эльвира Камалова һәм Эльмира Кашапова “Өмә көе” җырын шотланд волынкасы астында башкардылар.



Концертның режиссеры – Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Илдар Хәйруллин, идея авторы һәм программаның икенче режиссеры Татарстанның атказанган артисткасы, ансамбльнең сәнгать җитәкчесе Эльмира Кашапова.

Керәшеннәрнең “Бәрмәнчек” дәүләт фольклор ансамбле телевизион проектлар төшерүдә дә күп тапкырлар катнашты. Мәсәлән, 2012 елда “ТНВ” каналының “Аулак өй” телетапшыруы өчен “Бәрмәнчек”, “Олы көн”, “Тройсын” программалары төшерелде. 2013 һәм 2016 елларда ансамбль Россия телевидениесенең “Беренче канал”ындагы Анастасия Заволокина белән төшерелүче легендар программасы “Играй, гармонь, любимая!”да катнашты. Ә 2014 елда “ТНВ” каналында “Каравай” телевизион программасында “Бәрмәнчек” ансамбле “Пыкрау” йоласын күрсәтте.



